ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2019 № 1294

«2019-2021 нче елларга Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы мәдәни мирасын
саклау” муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2002 нче елның 25нче июнендәге “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында”гы 73-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 нчы елның 2 нче октябрендәге "Мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне саклау һәм алардан файдалану турында" 755-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, 2017 нче елның 29 нчы декабрендәге "2017-2030 нчы елларга Татарстан Республикасының мәдәни мирасын саклау стратегиясен раслау турында”гы 1116 нчы номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 нче елның 9 нчы июлендәге “Алабуга муниципаль районының муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында”гы 765 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының 2002 нче елның 20 нче сентябрендәге “Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау һәм файдалану турындагы законнарны үтәүне тәэмин итү чаралары турында” гы 824 нче номерлы Указын үтәү йөзеннән Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районының тарихи-архитектура һәм мәдәни мирас объектларын, аларның беренче тарихи йөзен саклап калу, шулай ук социаль-мәдәни, тарихи, архитектура һәм шәһәр төзелеше объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрне) югалтуга юл куймау максатларында, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарына шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүгә, Алабуга муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2019-2021 нче елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы мәдәни мирасын саклау» муниципаль программасын расларга (1 нче кушымта).

2. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «2019-2021 нче елларга Алабуга муниципаль районының мәдәни мирасын саклап калу» программасын гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны алдан карарга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча урынбасары О.А. Никитинага йөкләргә.

Җитәкче в.б. Л.Ф. Нургаянов